# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1 статья. **Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләре бирелә.”;

2) 4 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелүче субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләп чыгару Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча вәкаләтләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелүче

субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләп чыгару методикасы нигезендә әлеге Законга кушымта буенча башкарыла.”;

3) 7 статьяның икенче абзацында “мәгариф өлкәсендә вәкаләтле” сүзләрен “мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы” сүзләренә алмаштырырга;

4) 8 статьяда “мәгариф өлкәсендә вәкаләтле” сүзләрен “мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы” сүзләренә алмаштырырга;

5) 9 статьяның 1 пунктында “мәгариф өлкәсендә вәкаләтле” сүзләрен “мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы” сүзләренә алмаштырырга;

6) 10 статьяның 3 һәм 4 өлешләрендә “мәгариф өлкәсендә вәкаләтле” сүзләрен “мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы” сүзләренә алмаштырырга;

7) кушымтада:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**“БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕН МЕТОДИК ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТИ-ТЕХНОЛОГИК ТӘЭМИН ИТҮ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛӘРНЕ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ТАРАФЫННАН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН ҖИРЛЕ БЮДЖЕТЛАРГА БИРЕЛҮЧЕ СУБВЕНЦИЯЛӘРНЕҢ ГОМУМИ КҮЛӘМЕН ИСӘПЛӘП ЧЫГАРУ МЕТОДИКАСЫ**”;

б) 1 бүлекнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Методика белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирелгән дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү өчен кирәкле акчалар күләмен билгеләүнең ысулый нигезләрен урнаштыруга юнәлдерелә.”;

в) 2 бүлектә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетка билгеләнгән субвенция күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$S_i = Sm_i + Sy_i$ ,

монда:

$S_i$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга i-муниципаль берәмлеге өчен субвенция күләме;

$Sm_i$ – белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча вәкаләтләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар күләме;

$Sy_i$ – Татарстан Республикасының тапшырылган дәүләт вәкаләтләре өлкәсендә идарә чыгымнарын гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар күләме.”;

2, 2.1 һәм 2.2 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

3 пунктның беренче абзацында “Мәгариф учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итүне оештыру” сүзләрен “Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү” сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта “мәгариф учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итү” сүзләрен “белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү” сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның беренче абзацында “Мәгариф учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итү” сүзләрен “Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү” сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта “Мәгариф учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итү” сүзләрен “Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү” сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2013 елның 10 октябре
№ 75-ТРЗ